**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ КАЗКЕЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423761, село Казкеево,
ул. Первомайская,дом 2а,
Тел. 3-44-46

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ КӘЗКӘЙ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423761, Кәзкәй авылы,
Беренче май., 2а нчы йорт.
Тел.3-44-46

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**от 14.07.2021г** **№ 10**

**Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге Советының 20.06.2016 ел, №12 карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлегенең бюджет процессы нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «3. Агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә чираттагы финанс елында тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары муниципаль хокукый актлары нигезләмәләре исәпкә алына».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Кәзкәй авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Рәислек итүче Хуззятов Н.К.